**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 24 апрель № 242

г. Казань

Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне раслау хакында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 4 өлешнең 1 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә гомуми таләпләрне раслау хакында» 2015 ел, 18 май, 476 нчы карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар системасын камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлә торган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне (алга таба – Таләпләр) расларга.

2. Татарстан Республикасының сатып алулар буенча дәүләт комитетына әлеге карар кабул ителгән көннән соң өч эш көне эчендә Таләпләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сатып алулар өлкәсендәге бердәм мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының сатып алулар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 24 апрель, 242 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә
таләпләр

1. Әлеге документ түбәндәге хокукый актларның эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне (алга таба – Таләпләр) билгели:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан:

дәүләт идарәсенең беркетелгән функцияләре кысаларында вәкаләтләрне Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары һәм алар ведомствосындагы оешмалар тарафыннан тормышка ашыруга норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары һәм алар ведомствосындагы оешмалар тарафыннан сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең аерым төрләренә (шул исәптән товарлар, эшләр, хезмәтләрнең чик бәяләренә) карата таләпләрне билгеләү кагыйдәләрен;

дәүләт идарәсенең теркәлгән теркәлгән функцияләре кысаларында вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга, шулай ук ведомстводагы оешмаларның эшчәнлеген тәэмин итүгә норматив чыгымнарны;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, аларның территориаль органнары (бүлекчәләре) һәм алар ведомствосындагы оешмалар сатып ала торган аерым төр товарлар, эшләр, хезмәтләргә (шул исәптән товарлар, эшләр, хезмәтләрнең чик бәяләренә) таләпләр.

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба –ТР ИСТҮ) әлеге карар үз көченә кергән көннән соң 60 көн эчендә Таләпләрнең 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карарлары проектларын (алга таба – хокукый актлар проектлары) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Хокукый актлар проектларын җәмгатьчелек тикшерүе максатларында хокукый актлары проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына керткәнгә кадәр ТР ИСТҮ хокукый актлар проектларын һәм аларга аңлатмаларны Таләпләрнең 4 пунктында билгеләнгән вакытка «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасының рәсми сайтына (http://new.zakupki.gov.ru) (алга таба – сатып алулар

өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы) урнаштыра.

4. Җәмәгатьчелек тикшерүе максатларында фикер алышулар үткәрү вакыты Таләпләрнең 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына урнаштырган көннән соң җиде календарь көненнән кимрәк була алмый.

5. ТР ИСТҮ җәмәгать берләшмәләре, юридик һәм физик затларның әлеге Таләпләрнең 4 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнгән вакытта электрон яки язма рәвештә кергән тәкъдимнәрен гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында Россия Федерациясе законнары нигезендә карап тикшерә.

6. ТР ИСТҮ җәмәгать берләшмәләре, юридик һәм физик затларның мөрәҗәгатьләрен карап тикшергән көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча бу мөрәҗәгатьләрне һәм аларга җавапларны сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына урнаштыра.

7. Әгәр җәмәгатьчелек тикшерүе максатларында фикер алышу процессында җәмәгать берләшмәләре, юридик һәм физик затлардан Таләпләрнең 1 пунктында күрсәтелгән һәм сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына урнаштырылган хокукый актлар проектларына тәкъдимнәр һәм/яки искәрмәләр керсә һәм мондый тәкъдимнәр һәм/яки искәрмәләр мондый проектларны урнаштырган орган тарафыннан нигезле дип танылса, ТР ИСТҮ әлеге хокукый актлар проектларына үзгәрешләр кертә.

8. Әлеге Таләпләрнең 1 пунктының бишенче һәм алтынчы абзацларында күрсәтелгән хокукый актлар алар кабул ителгән көннән соң җиде эш көне эчендә сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына урнаштырыла һәм әлеге Таләпләрдә каралган тәртиптә елына кимендә бер тапкыр актуальләштерелергә тиеш.